

Татар халкынын боек шагыйре Габдулла Тукайнын тууына быел 136 ел була. 27 яшь гомер генә яшәп калса да, әдипнен татар тарихы, татар әдәбиятында калдырган олеше бәялəп бетергесез.
Бу айда боек шагыйребезне искə алмый калучылар татар илендə сирəктер. Регионыбызнын авыллары мəктəп-лəрендə, мəдəният йортларында, балалар бакчаларында бер ел да Габдулла Тукай туган конен билгелəми калмыйлар. Һəм менə ул чор житте.      Мəсəлəн, мəктəплəрдə Габдулла Тукаебыз биографиясе һəм ижатына багышлап ачык дəреслəр, кичəлəр, викториналар һəм башка кvпторле чаралар оештырыла. Клублар, балалар бакчалары да бу эшлəрдəн читтə калмыйлар.
- Балалар белəн Габдулла Тукайнын шигырьлəрен укып, сойлəшеп, фикерлəр уртаклашып, ахырдан бергəлəшеп «Туган тел»не жырладык. Шундый жылы, рəхəт очрашу булды, - дип уртаклашты Кадошкино районы Большие Поляны топ мəктəбе директоры Светлана Наиль кызы Кильдеева сайтларында. Дəвам итеп ул: «Менə инде йоз елдан артык һəр бала яраткан татар шагыйренен əсəрлəрен зур кызыксыну белəн укый һəм хəтта аларны яттан белə. Большие Поляны топ гомуми белем бирv мəктəбендə «Тукай доньясына сəяхəт» дип исемлəнгəн ачык дəрес булып узды, татар теле һəм əдəбияты укытучысы Зəйнəб Хосəен кызы Кильдеева олкəн сыйныф укучыларын Тукайнын биографиясе белəн таныштырды.
Кыска гына гомер яшəп, Тукай бик зур мирас калдырган, анын яртысын диярлек балалар əдəбияты алып тора. Туган телгə, туган якка, анын табигатенə мəхəббəт безнен балалар очен язылган шигырьлəр һəм əкиятлəрдəн барлыкка килə.
Балалар шагыйрьнен биография-сеннəн бик кvп яналыклар белделəр, замандашларынын татар халкынын боек улы – Габдулла Тукай турында хатирəлəрен тынладылар. Туган тел, гади халык тормышына кагылышлы шигырьлəр сойлəделəр «Таз», «Печəн базары, яхуд яна Кисекбаш», «Шvрəле» əкият – поэмалары белəн таныштылар. Дəрес барышында укучылар шагыйрьнен əкиятлəренə һəм шигырьлəренə куелган сорауларга жавап бирделəр, иллюстрациялəр буенча табышмаклар чиштелəр, «Бала белəн кvбəлəк» шигырен сəхнəлəштерделəр. Шулай ук анын əсəрлəре мотивлары буенча тошерелгəн видеофильмнар да кvрсəтелде («Эш беткəч, уйнарга ярый», «Су анасы», «Туган авыл»). Сəяхəт ахырында балалар бик телəп «Туган тел» жырын башкардылар, ул инде татар теленə гимнга əверелде».